ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» апреля 2020 ел № 110

**Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2019 елның 6 декабрендәге 471 номерлы карары белән расланган балаларны карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең күләменә, мәгариф оешмаларына күчерелгән балага карата төзәтмәләр коэффициентына үзгәрешләр кертү турында**

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында ата-ана түләвен исәпләгәндә төзәтү коэффициентларын куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының «Ата-ана түләвен исәпләү турында» 2020 елның 19 мартындагы 3419/20 номерлы хатын, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2020 елның 13 мартындагы 03-15/1859 номерлы ата-аналар түләве күләменә төзәтмә коэффициентларын кулланганда исәпләү мисалы турында хатын үтәү максатыннан, Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 2 июлендәге 546 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2019 елның 06 декабрендәге 471 номерлы карарының 1 пунктның дүртенче абзацына, яңа редакциядә бәян итеп түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын 2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына исәпләнгән баланы карап торган һәм караган өчен ата-аналар түләве күләменә күчеш чорына карата - 2 айдан 3 яшькә кадәрге балалар өчен - 0,865, белем бирү мөнәсәбәтләрен туктатуга кадәр булган балалар өчен - 0,865.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының финанс-бюджет палатасында түбәндәгеләрне тәэмин итәргә: әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын финанслау нормативлары нигезендә мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын финансларга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

4. Үзгәрешләр әлеге карарның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм үз көченә кергәнче- 2020 елның 01 апреленә барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**